КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 декабрь г.Казань № 1638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары белән расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1475 нче, 2023 ел, 18 апрель, 487 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү

чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

дүртенче абзацта «җитәкче» сүзеннән соң «яисә вәкаләтле зат» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «җитәкче» сүзеннән соң «яисә вәкаләтле зат» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «җитәкче» сүзеннән соң «яисә вәкаләтле зат» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«идарәче компаниянең җитәкчесе яисә вәкаләтле заты кул куйган, идарәче компаниянең җитәкчесе яисә баш бухгалтеры дисквалификацияләнгән затлар реестрында булмау, идарәче компания экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, йә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау турында белешмә кәгазе;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 4.6 пункты нигезендә Килешүгә өстәмә килешү төзелгән очракта, әлеге пунктның ундүртенче абзацында күрсәтелгән документ идарәче компания тарафыннан Вәкаләтле органга тапшырылмаска мөмкин.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Агымдагы финанс елында субсидия алу өчен идарәче компания Вәкаләтле органга агымдагы елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча түбәндәге документларны тапшыра:

тиешле Россия кредит оешмалары һәм (яисә) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе тарафыннан таныкланган кредит буенча ссуда бурычы күләмен раслый торган ссуда счеты буенча өземтә;

түләү йөкләмәләренең һәм башка документларның күчермәләре, шул исәптән әлеге пунктның унбишенче абзацын исәпкә алып, кредит шартнамәсе буенча исәпләнгән төп бурычны һәм процентларны түләү фактын раслаучы банк ордерларының күчермәләрен;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү турында гариза;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә белешмә-исәп (алга таба - белешмә-исәп);

индустриаль парк инфраструктурасын төзүнең проект-смета документациясе күчермәсен;

индустриаль парк инфраструктурасын булдыруга подряд оешмасы белән төзелгән шартнамәләрнең, контрактларның, килешүләрнең күчермәләрен;

билгеләнгән тәртиптә таныкланган проект-смета документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәләрен;

индустриаль парк инфраструктурасын булдыру буенча башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләрен;

башкарылган проект-тикшерү эшләрен кабул итү-тапшыру актларының, авторлык күзәтчелеге, төзелеш контроле күчермәләрен (тиешле чыгымнарны каплауга кредит чараларын кулланганда);

индустриаль парк инфраструктурасы объектларын техник шартлар эшләүгә һәм технологик тоташтыруга (тиешле чыгымнарны каплауга кредит акчаларыннан файдаланганда) актларның күчермәләрен;

КС-2 формасы буенча индустриаль парк  инфраструктурасын булдырырга башкарылган эшләрне  кабул итү турында актларның күчермәләрен;

башкарылган эшләр бәясе һәм КС-3 формасы буенча индустриаль парк инфраструктурасын булдыруга чыгымнар турында белешмәләр күчермәләрен;

дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе белән расланган индустриаль парк инфраструктурасын төзү бәясенең җыелма смета исәпләүләре күчермәләрен.

Процентлар түләү буенча йөкләмәләре булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче Вәкаләтле органга Россия кредит оешмасы һәм (яисә) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе тарафыннан таныкланган процентлар түләү йөкләмәләренең үтәлеше турында белешмәне тапшыра.

Идарәче компания Вәкаләтле органга бу пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән документларны электрон чыганакта сканерланган рәвештә тапшырырга хокуклы.»;

4.1 пунктта:

өченче абзацта «2.1, 2.2 « саннарыннан соң «, 3.2» саннарын өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә үткәргәннән тикшерүдән соң өч эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 3.2 пунктының алтынчы - сигезенче, унынчы - ундүртенче абзацларында  күрсәтелгән документларны тапшырылган документларның дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект (смета) документларының туры килүен раслау өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җибәрә яисә әлеге Тәртипнең 4.4 пункты нигезендә,  моның өчен нигез булган очракта, субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

4.2 пунктта «алтынчы - уникенче» сүзләрен «алтынчы - сигезенче, унынчы - ундүртенче» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның өченче абзацында «алтынчы - уникенче» сүзләрен «алтынчы - сигезенче, унынчы - ундүртенче» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.7 пункт өстәргә:

«4.7. Идарә итүче компания Килешү төзүдән түбәндәге очракларда читләшкән дип санала:

әлеге Тәртипнең 4.5 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән вакытта Килешү проектына имза куймаган;

Вәкаләтле органга заявкага туры килми торган шартларда Килешү төзүдән баш тарту турында хәбәрне яисә Килешү төзү турындагы тәкъдимне үз эченә алган язма мөрәҗәгать җибәргән»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 17 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 декабрь, 1638 нче карары редакциясендә)

Форма

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркы буенча / «Этилен-600» индустриаль паркы буенча исәп-хисап белешмә кәгазе

| Т/с | Объект исеме | Өстәлгән кыйммәткә салымсыз төзелешнең смета кыйммәте | ____ дан ______ кадәрге чорга башкарылган эшләр кыйммәте – өстәлгән кыйммәткә салымсыз барлыгы, сум | Кредит шартнамәсе буенча кредит суммасы, сум | ____ дан ______ кадәрге чорга кредит шартнамәсе буенча алынган кредит суммасы, сум | Кредит килешүе буенча калган өлеше __________ ______, сум | ___________ _ датасына карата кредит шартнамәсе буенча төп бурыч суммасы, сум | ____ дан ______ кадәрге чорга кредит шартнамәсе буенча төп бурычны каплау суммасы, сум | ____ дан ______ кадәрге чорга кредит шартнамәсе буенча процентларны каплау суммасы, сум | Сорала торган чорга элек бирелгән субсидиянең гомуми суммасы, сум | Шул исәптән чыгымнарны каплауга | | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 декабрь, 1003 нче; 2019 ел, 23 апрель, 332 нче* карарлары буенча элек бирелгән субсидиянең гомуми суммасы, сум | Шул исәптән | | Заявка биргән датага субсидиянең иң чик күләме, сум | Түләнергә тиешле чорга субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | 2022 ел | | 20__ ел | | | 2017 ел | 20__ ел | | |
| | | | | | | | | | | | төп бурыч буенча | процентлар буенча | төп бурыч буенча | процентлар буенча | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6=8+9 | 7=5–(8+9) | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19=((3–16)+ +10)×0,999 –11 | 20=(9+10)×0,999, ләкин 19 баганадагы |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | мәгънәсеннән дә артык түгел |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 декабрь, 1003 нче карары («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркына карата кулланыла);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 332 нче карары.

Субсидия күләме _____________ сум.

Идарә итүче компания җитәкчесе __________________ ____________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Идарә итүче компаниянең вәкаләтле заты ___________ _______________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы - булган очракта))

М.У. (булганда)

_______________________________________________